Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сораулары
(мәктәп туры, 2017-2018 уку елы). 10 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 60 минут.
Максималь балл – 45.

I. Теоретик биремнәр. (7 балл)

1. XX йөз башы татар әдәбиятында мөрәҗәгать ителгән реализм иҗат юнәлешенә мөнәсәбәтле ике иҗат агымын аерып билгеләгез һәм исемнәрен язып куегыз. (4 балл)

2. Түбәндә аталган әсәрләрнең кайсылары XX йөз башы татар әдәбиятына карый. (3 балл)
А) “Хисаметдин менла”
Б) “Китмибез!”
В) “Акчарлаклар”
Г) “Меңнәр, яки гүзәл кыз Хәдичә”
Д) “Яшь йөрәкләр”

II. Әдәби әсәргә кагылышлы биремнәр. (23 балл)

1. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда геройларның эш-гамәлләре аша нинди сыйфатлар хуплана, ниндиләре тәнкыйтьләнә, кире кагыла? Аерып куеп, санап чыгыгыз. (10 балл)

2. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда җиткерелгән төп идеяне ачыклап языгыз, укучыга нинди фикер әйтелә? (5 балл)

3. Ф.Әмирханның “Хәят” повестенда Хәят образын сурәтләү барышында кулланылган әдәби алымнарны билгеләп языгыз. (8 балл)

III. Иҗади эш. (15 балл)

Төрле тел-сурәтләү чараларын кулланып, үзегез теләгән бер предметны детальләп сурәтләп языгыз.